**СОВЕТ УСАДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Усады, ул. Советская, 41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСАД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Усад авылы, Совет урамы,41

тел./факс 8(84365) 73-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**8 октября 2020 г.** **№ 6**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, «Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Усад авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Советының 2014 елның 29 декабрендәге 296 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяны түбәндәге эчтәлекле 1.1. өлеш белән тулыландырырга:

«1.1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары проект инициаторлары буларак инициатив проектны тәкъдим итәргә мөмкин.»;

2) 14 статьяның 4 өлешен түбәндәге эчтәлекле 7 пункт белән тулыландырырга:

«инициатив проект буенча фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар 2021 елның 1 январеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Усад авыл җирлеге башлыгы Забиров Ф.А. йөкләргә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Ф.А.Забиров